**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**С О В Е Т**
**Нижнекамского муниципального района**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама муниципаль районы**
**С О В Е Т Ы**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 70** **2018 елның 28 ноябре**

**Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы шәһәр төзелешен проектлаштыру җирле нормативларын раслау турында» 2017 елның 15 декабрендәге 69нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районыУставына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1.Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы шәһәр төзелешен проектлаштыру җирле нормативларын раслау турында» 2017 елның 15 декабрендәге 69нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 5.2.11 пунктында «чикләр» сүзен төшереп калдырырга;
- 6.3.11 пунктының 6 абзацында «балык саклау зоналары» сүзен төшереп калдырырга;
- 6.1.6 пунктында «мәйданнары» сүзләрен «торак пункт чикләре артында урнашкан һәм мәйданнарда торган җир кишәрлекләре» сүзләренә алмаштырырга, «аларның ятмалары урыннарында» сүзләрен «файдалы казылмалар ятмалары урыннарында торак пункт чикләре артында» сүзләренә алмаштырырга. ☐

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы А.Р. Метшин